**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№ М 388**
**17.08.2018**

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында Нигезнамәне раслау хакында

Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турындагы кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 48 маддәсе, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында Нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. Түбәндәге карарлар үз көчен югалткан дип танырга:

1) шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында»гы 2007 елның 16 маендагы 181 нче карары;

2) шәһәр Хакименең 2007 елның 16 маендагы 181 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында»гы 2007 елның 8 октябрендәге 381 нче карары;

3) шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турындагы Нигезнамәнең 22 пунктына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 25 июлендәге 299 нчы карары;

4) шәһәр Хакименең 2007 елның 16 маендагы 181 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында»гы 2015 елның 25 июнендәге М 198 нче карары;

5) шәһәр Хакименең «шәһәр Хакименең аерым карарларын туктатып тору турында» 2018 елның 17 апрелендәге М 164 нче карары.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 апреленнән хасил булган хокук мөнәсәбәтләре өчен гамәлдә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага, Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Хакименең
2018 елның 17 августындагы
М 388 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә гарантияләр турында
Нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турындагы кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 Карары нигезендә әлеге Нигезнамә Яр Чаллы шәһәренең (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) муниципаль хезмәткәр вазыйфасын биләүче затларга өстәмә гарантияләр бирүнең төрләрен, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Нигезнамәдә каралган өстәмә гарантияләр бирүгә чыгымнар Башкарма комитет тарафыннан һәр елны чираттагы финанс елына тиешле җирле үзидарә органын (муниципаль органны) тотуга шәһәр бюджеты проектын эшләгәндә карала.

3. Әлеге Нигезнамәдә каралган өстәмә гарантияләр бирүгә чик чыгымнар һәр елны чираттагы финанс елына шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы Карары белән билгеләнә

4. Әлеге Нигезнамә нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге өстәмә гарантияләр билгеләнә:

1) торак сатып алу яки төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидия;

2) авыруларны стационарда дәвалаганнан соң санаторийда дәвалау кирәклегенә бәйле рәвештә, санатор-курорт юлламасының бәясен түләү (алга таба – санатор-курорт юлламасы);

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә, биләгән вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм эштән җибәрелгәндә картлык буенча иминият пенсиясен алуга хокукы булганда, бер тапкыр түләү.

2 бүлек. Торак сатып алу яки төзүгә бер тапкыр бирелә торган
субсидияне бирү тәртибе һәм шартлары

5. Муниципаль хезмәткәргә торак сатып алу яки төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидия (алга таба – бер тапкыр бирелә торган субсидия) бер үк вакытта түбәндәге шартлар булганда бирелә:

1) бер тапкыр бирелә торган субсидиянең элек түләнгән булмавы;

2) муниципаль хезмәткәрнең әлеге Нигезнамәнең 7 пункты нигезендәге документларны теркәп, бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гариза язуы; (алга таба – гариза);

3) Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) бер елдан да ким булмаган стажы булу;

4) муниципаль хезмәткәр гаиләсенең бер әгъзасының торак хокукы объектларында гомуми мәйдан белән тәэмин ителүенең тулаем дәрәҗәсе муниципаль хезмәткәр гаиләсенең бер әгъзасының 12 квадрат метрдан ким булган торак мәйданы булу яки билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак бүлмәдә яшәве;

5) бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гариза язганга кадәр биш ел эчендә муниципаль хезмәткәр һәм (яки) аның гаиләсе тарафыннан муниципаль

хезмәткәрнең яшәү шартларын начарайтуга китергән, торак бүлмәләрне сату-алу белән бәйле гражданлык-хокукый характердагы операцияләр башкарылмау.

6. Әлеге Нигезнаменең максатларында муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзалары дип аның белән бергә яшәүче балалары, ата-анасы, ире (хатыны), муниципаль хезмәткәрнең бертуган абыйлары һәм бертуган апаларын аңларга кирәк.

7. Муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турындагы мәсьәләне карау өчен муниципаль хезмәткәр:

1) әлеге Нигезнаменең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча тиешле җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе исеменә гариза бирә;

2) әлеге Нигезнаменең 2 нче кушымтасында каралган форма буенча барлык кирәкле мәгълүматларны күрсәтеп анкета тутыра;

3) дәлилләүче түбәндәге документларны бирә:

- муниципаль хезмәткәрнең бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү өчен кирәкле муниципаль стажын дәлилләүче хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

- муниципаль хезмәткәрнең торак бүлмәсенә хокукын билгеләүче документлар күчермәсе (приватизация килешүе, сату-алу килешүе, бүләк итү килешүе, наем килешүе, ордер һәм башкалар);

- муниципаль хезмәткәрнең аның гаилә әгъзалары белән туганлык мөнәсәбәтләрен дәлилләүче документлар күчермәләре (язылышу турында таныклык, туу турында таныклык);

- компетентлы органның (вазыйфаи затның) муниципаль хезмәткәрнең яшәү өчен биләгән торак бүлмәсен яшәү өчен яраксыз дип тануы турындагы хокукый актының күчермәсе (торак бүлмәне яшәү өчен яраксыз дип тану очрагында).

8. Әлеге Нигезнаменең 5 нче пунктында каралган нигезләр булганда, җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында Яр Чаллы шәһәре Хакименә юллама җибәрә (алга таба – юллама);

9. Гаризаларны һәм аңа теркәлгән документларны карау бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссия тарафыннан юллама алынган көннән алып бер ай срокта гамәлгә ашырыла (алга таба – Комиссия). Комиссияне, аның составын һәм эш регламентын формалаштыру тәртибе, шулай ук Комиссия әгъзаларының җаваплылыгы Яр Чаллы шәһәре Хакиме тарафыннан билгеләнә.

10. Гариза һәм аңа теркәлгән документлар алынганнан соң бер ай эчендә комиссия:

1) гаризага теркәлгән документларның әлеге Нигезнаменең 7 пунктына туры килүен тикшерә;

2) бирелгән документларда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;

3) муниципаль хезмәткәргә әлеге Нигезнаменең 5 пунктына туры китереп бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагучы хәлләрнең булуын билгели;

4) муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидияне бирү яки бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

11. Бер тапкыр бирелә торган субсидияне бирү яки бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагу турындагы карар Комиссия тарафыннан әлеге Нигезнаменең 3, 4 пунктларында каралган форма буенча кабул ителә.

12. Муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була ала:

1) муниципаль хезмәткәргә әлеге Нигезнаменең 5 пунктына туры китереп бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагучы хәлләрнең булуы;

2) документларда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәве;

3) әлеге Нигезнаменең 7 пунктында каралган документларның бирелмәве яки аларда төгәлсезлекләр булу.

13. Әлеге Нигезнаменең 12 пунктында каралган нигезләр булмаганда, Комиссия муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидияне бирү турында карар кабул

итә.

14. Комиссия квартал саен бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән муниципаль хезмәткәрләрнең исемлеген формалаштыра (алга таба – исемлек) һәм аны шәһәр Хакименә расларга җибәрә.

15. Шәһәр Хакиме раслаган исемлекләр нигезендә Башкарма комитетның финанс идарәсе (алга таба – финанс идарәсе), элек расланган исемлекләрне исәпкә алып, бер тапкыр бирелә торган субсидияләрне бирү турында карар кабул ителгән муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм исемлеген (алга таба – бердәм исемлек) формалаштыра.

16. Түбәндәге нигезләрнең берсе булганда, муниципаль хезмәткәр бердәм исемлектән төшереп калдырыла:

1) бер тапкыр бирелә торган субсидияләрне бирүнең әлеге Нигезнамәнең 5 пунктында каралган шартларын югалту;

2) Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидияне бирү турында карар кабул итү өчен нигез булып хезмәт иткән вазыйфаи затларның хокуксыз гамәлләре ачыклану;

3) Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) муниципаль хезмәтнең туктатылуы;

4) муниципаль хезмәткәрнең үзен бердәм исемлектән чыгару турында гариза бирүе.

17. Муниципаль хезмәткәрне бердәм исемлектән чыгару Комиссиянең хәл итүе буенча шәһәр Хакиме карары белән башкарыла.

18. Муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган субсидия, аларның бердәм исемлектә урнашкан чираты буенча, чираттагы финанс елына шәһәр бюджетында бу максатларга каралган акчалар чикләрендә бирелә.

19. Бирелә торган субсидиянең күләме түбәндәге формуладан чыгып билгеләнә:

С = (НП – УН) × НС × К формуласында:

С – бер тапкыр бирелә торган субсидиянең күләме;

НП – Россия Федерациясе Җир кодексының 50 маддәсе нигезендә билгеләнгән социаль наем килешүе буенча торак мәйдан бирү нормасы;

УН – Россия Федерациясе Җир кодексының 50 маддәсе нигезендә билгеләнгән социаль наем килешүе буенча торак мәйдан бирүне исәпкә алу нормасы;

НС – Яр Чаллы шәһәрендә 1 кв.м. торакның норматив бәясе;

К – Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) муниципаль хезмәтнең гомуми стажыннан чыгып билгеләнә торган төзәтү коэффициенты:

| гомуми муниципаль хезмәт стажы | 1-3 ел | 3-6 ел | 6-9 ел | 9-12 ел | 12-15 ел | 15 -18 ел | 18 һәм аннан да күбрәк ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төзәтү коэффициенты | 0,1 | 0,2 | 0,3 | 0,5 | 0,7 | 0,9 | 1 |

## 3 бүлек. Муниципаль хезмәткәргә санатор-курорт юлламасының бәясен түләү тәртибе һәм шартлары

20. Муниципаль хезмәткәргә санатор-курорт юлламасының бәясен түләү аның бәясе күләмендә башкарыла, ләкин ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасының өч окладыннан да артык түгел, сәламәтлек саклау учреждениесеннән бирелгән тиешле медицина белешмәсе булу шарт.

21. Санатор-курорт юлламасының бәясен түләү җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенең муниципаль хезмәткәр гаризасы буенча кабул иткән карары нигезендә, ике елга бер тапкырдан да ешрак башкарылмый. Санатор-курорт юлламасының бәясен түләү турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) стационарда дәвалаганнан соң санатор-курорт дәвалануының кирәклеге турында сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина белешмәсе;

2) санатор-курорт юлламасының бәясен дәлилләүче документлар.

### 4 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә, билгән вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм картлык буенча иминият пенсиясен алуга хокукы булганда эштән җибәрелгәндә бер тапкыр түләнә торган түләү

22. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә, биләгән вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм картлык буенча иминият пенсиясен алуга хокукы булганда эштән җибәрелгәндә бер тапкыр түләнә торган түләү (алга таба – бер тапкыр түләнә торган түләү) Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турындагы кодексы нигезендә эшләнгән.

23. Биләгән вазыйфасыннан азат итү һәм картлык буенча иминият пенсиясен алуга хокукы булганда эштән җибәрү дигәндә муниципаль хезмәттән «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе алуга хокук бирә торган яшькә җитү буенча эштән җибәрү дип аңларга кирәк.

24. Муниципаль хезмәткәргә биләгән вазыйфасыннан азат ителү һәм картлык буенча иминият пенсиясен алуга хокукы булганда эштән җибәрелү очрагында, бер тапкыр түләнә торган түләү, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алуга кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында 5 елдан да ким хезмәт куймаганда, түбәндәге коэффициентларны исәпкә алып башкарыла:

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел һәм аннан соңгы еллар | Муниципаль хезмәт стажын исәпкә алу коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең минималь стажы | 16 яшь | 16 яшьтә 6 ай | 17 яшь | 17 яшьтә 6 ай | 18 яшь | 18 яшьтә 6 ай | 19 яшь | 19 яшьтә 6 ай | 20 яшь | 5 |
| | 19 яшь | 19 яшьтә 6 ай | 20 яшь | 20 яшьтә 6 ай | 21 яшь | 21 яшьтә 6 ай | 22 яшь | 22 яшьтә 6 ай | 23 яшь | 7 |
| | 21 яшь | 21 яшьтә 6 ай | 22 яшь | 22 яшьтә 6 ай | 23 яшь | 23 яшьтә 6 ай | 24 яшь | 24 яшь 6 ай | 25 яшь | 9 |
| | 26 яшь | 26 яшьтә 6 ай | 27 яшь | 27 яшьтә 6 ай | 28 яшь | 28 яшьтә 6 ай | 29 яшь | 29 яшьтә 6 ай | 30 яшь | 10 |

*Муниципаль хезмәтнең минималь стажы тиешле елда гамәлдә булган Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексына кушымта нигезендә билгеләнә.

25. Бер тапкыр түләнә торган түләүнең күләме муниципаль хезмәткәр стажын исәпкә алган коэффициентны эштән азат ителгән көнгә айлык акча күләменә тапкырлау юлы белән билгеләнә.

26. Бер тапкыр түләнә торган түләүнең күләмен билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгару муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән киткән көненә

гамәлгә ашырыла һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

27. Бер тапкыр түләнә торган түләүне билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык хезмәт хакы составына түбәндәгеләр кертелә:

1) вазыйфаи оклад;

2) вазыйфаи окладка тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә;

3) вазыйфаи окладка классны чин өчен айлык өстәмә;

4) вазыйфаи окладка муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен айлык өстәмә;

5) аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләр үтәгән өчен премияләр;

6) айлык акчалата бүләкләү;

7) ел саен бирелә торган чираттагы түләүле ялга киткәндә бер тапкыр түләнә торган түләүнең 1/12 өлеше күләме;

8) нормада булмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләве;

9) төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый акт проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый акт проектларын әзерләү һәм редакторлык итү һәм аларны юрист яки югары юридик белемгә ия башкаручы сыйфатында визалау кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү (юридик хезмәт өчен түләү);

10) вазыйфаи окладка фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе өчен айлык өстәмә;

11) вазыйфаи окладка Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен айлык өстәмә;

12) вазыйфаи окладка дәүләт сере булып саналган мәгълүматлар белән эшләгән өчен айлык өстәмә.

28. Бер тапкыр түләнә торган түләү муниципаль хезмәткәргә җирле үзидарә органы җитәкчесенең бер тапкыр түләнә торган түләү турындагы хокукый акты нигезендә ахыргы исәп-хисап ясаганда башкарыла.

29. Бер тапкыр түләнә торган түләү бер тапкыр башкарыла. Биләгән вазыйфасыннан азат ителгән һәм эштән җибәрелгән, картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукы булган һәм алга таба муниципаль хезмәте туктатылган граждан муниципаль хезмәткә алынган очракта, аңа бер тапкыр түләнә торган түләү башкарылмый.

30. Бер тапкыр түләнә торган түләү түбәндәге очракларда муниципаль хезмәткәргә түләнми:

1) эштән азат иткән моментка аңа карата дисциплинар җаваплылык каралган булу;

2) аналогик түләүне элек Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте, Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләт гражданлык һәм муниципаль хезмәте туктатылганда алган булу.

31. Бер тапкыр түләнә торган түләүне гамәлгә ашыруга нигез булып тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләгәндә исәпкә алына торган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан муниципаль хезмәткәрнең Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтнең тулаем стажы турындагы запросыннан алынган мәгълүмат тора.

## 5 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

32. Әлеге Нигезнамәдә каралган өстәмә гарантияләрне финанс ягыннан тәэмин итү мөмкинлеген кире кагуга нигезләр булган очракта, Яр Чаллы шәһәре Хакиме карары белән әлеге Нигезнамәнең яисә аның аерым бүлекләренең гамәлдә булуы туктатылырга мөмкин.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары — Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә гарантияләр
турында Нигезнамәгә
1 нче кушымта

_______________________________________________________

жирле үзидарә органы житәкчесе вазыйфасының тулы исеме

_______________________________________________________

(муниципаль органының) Фамилиясе И. А.и. юнәлеш килешендә

_______________________________________________________

муниципаль хезмәт вазыйфасының тулы исеме

_______________________________________________________

(жирле үзидарә органын (муниципаль органны күрсәтеп),

_______________________________________________________

Фамилиясе И.А.и. иялек килешендә

Гариза

Минем гаиләнең бер әгъзасының торак хокукы объектларында гомуми мәйдан белән тәэмин ителүенең тулаем дәрәҗәсе бер әгъзага 12 квадрат метрдан ким булган торак мәйданы булу/мин һәм минем гаилә әгъзалары билгән торак бүлмәнең яшәү өчен яраксыз дип танылуы сәбәпле *(кирәгенең астына сызарга)*
Миңа бер тапкыр түләнүче субсидияне торак__________________ бирүне сорыйм.
сатып алуга/ төзүгә

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, торак сатып алу һәм төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турындагы мәсьәләләрне карый торган комиссиянең әлеге гаризада һәм тиешле органнарда теркәлгән документларда күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүенә ризалык бирәбез.

Әлеге гаризада һәм тиешле органнарда теркәлгән документларда күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә, алар турында бер ай срокта торак сатып алу һәм төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турындагы мәсьәләләрне карый торган комиссиягә хәбәр итәргә йөкләмә алам.

Теркәлә:
1. ______________________________________________________;
2. ______________________________________________________;
3. ______________________________________________________;
4. ______________________________________________________;
5. ______________________________________________________.

Муниципаль хезмәткәр: _________________
имзасы

Хезмәткә яраклы
гаилә әгъзалары:

1. ____________________________________________________________________;
2. ____________________________________________________________________;
3. ____________________________________________________________________;
4. ____________________________________________________________________;
5. ____________________________________________________________________.

хезмәткә яраклы барлык гаилә әгъзаларының фамилияләре И.А.и. һәм имзалары

«___» ______________ 20___

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә гарантияләр
турында Нигезнамәгә
2 нче кушымта

АНКЕТА

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме
___________________________________________________________________

2. Яшәү урыны адресы:
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________
________________

өй тел.__________________ эш тел.__________________ .

3. Паспорт сериясе ________ номеры ____________________ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән ____________________
___________________________________________________________________
________

4. Муниципаль хезмәт вазыйфасы ___________________________________________
___________________________________________________________________
________

5. Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) гомуми муниципаль хезмәт стажы __________ ел.

6. Минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзаларының саны________

7. Мин һәм минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзалары милек хокукында түбәндәге торак мәйданны (өлешне):
Мин:_______________________________________________________________
__________

Минем гаилә әгъзалары:
1)_________________________________________________________________
_______
___________________________________________________________________
________;
2)_________________________________________________________________
_______
___________________________________________________________________
_______;3)__________________________________________________________
________________
___________________________________________________________________
________ биләп торабыз;

нинди, кайда, нинди нигездә

Фамилиясе И.А.и. (туганлык дәрәҗәсе): нинди, кайда, нинди нигездә

гомуми мәйданы _________________ кв.м., торак мәйданы _________________ кв.м.

8. Мин һәм минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзалары наем килешүе буенча (ордер) гомуми мәйданы _________________ кв.м., торак мәйданы _________________ кв.м. булган торак бүлмәсен биләп торабыз.

9. Мин һәм минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзалары биләгән торак бүлмәсе яшәү өчен яраксыз дип
танылды____________________________________________________________________________

танылмады/компетентлы органның (вазыйфаи затның) исеме,
хокукый акт реквизитлары
____________________________________________________________________________________

торак бүлмәнең яшәү өчен яраксыз булуын тану турында

10. Бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гариза язганга кадәр биш ел эчендә минем яисә минем гаилә әгъзалары тарафыннан минем яшәү шартларын начарайтуга китергән торак бүлмәләрне сату-алу белән бәйле гражданлык-хокукый характердагы операцияләр башкарылмады.
11. Торак сатып алу һәм төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидия миңа элек бирелмәде.

Әлеге анкетадагы мәгълүматларның күрсәтелгән датага дөрес һәм төгәл булуын раслыйм.

Муниципаль хезмәткәр:
_____________________________________________________________________.
имзасы Фамилиясе И.А.и.

«___»______________20__ел.

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә гарантияләр
турында Нигезнамәгә
3 нче кушымта

Торак сатып алу яки төзү өчен муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссия

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турындагы Нигезнамәнең 10 пункты нигезендә торак сатып алу яки төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турында

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

муниципаль хезмәткәр вазыйфасының тулы исеме Фамилиясе И А.и
гаризасын караганнан соң комиссия билгеләде:

1. ________________________________________ һәм аның гаилә әгъзалары:
муниципаль хезмәткәрнең Фамилиясе И.А.и

___________________________________________________________________

_____ адресы буенча яши,

биләгән торак бүлмәнең гомуми мәйданы ____________кв.м.ны тәшкил итә,
биләгән торак бүлмәнең торак мәйданы ______________кв.м.ны тәшкил итә.

2. Торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия ____________________

Фамилиясе И.А.и.
бирелмәгән.

3. ________________________________________________
Фамилиясе И.А.и.

Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарындагы (муниципаль органнардагы) муниципаль хезмәт стажы ___________ елны тәшкил итә.

4. _______________________

(Фамилиясе И.А.и.)
гаиләсенең бер әгъзасының гомуми мәйдан белән тәэмин ителүенең тулаем дәрәҗәсе ___________ кв.м.ны тәшкил итә.

__________елның _______санлы карары белән__________________________Фамилиясе И.А.и. ______________биләгән торак бүлмә яшәү өчен яраксыз дип танылды *(торак бүлмә яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта күрсәтелә)*

.5. _________________________________ (Фамилиясе И.А.и.)

торак сатып алу һәм төзүгә субсидия бирү турында гариза язганга кадәр биш ел эчендә аның яшәү шартларын начарайтуга китергән сату-алу белән бәйле операцияләр башкарылмады.

Комиссия Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турындагы Нигезнамәнең 13 пункты нигезендә карар бирде:

1. __________________(Фамилиясе И.А.и.) торак сатып алу һәм төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидияне

______________ сум күләмендә бирергә.

2. _________________________(Фамилиясе И.А.и.) торак сатып алу һәм төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында карар кабул ителгән муниципаль хезмәткәрләр исемлегенә кертергә.

Комиссия рәисе _______________________ _______________

И.А.и. фамилиясе

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә гарантияләр
турында Нигезнамәгә
4 нче кушымта

Торак сатып алу яки төзү өчен муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча
комиссия

Комиссия Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турындагы Нигезнамәнең 12 пункты нигезендә торак сатып алу яки төзүгә бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турында

______________________________________________________________

муниципаль хезмәткәр вазыйфасының тулы исеме, Фамилиясе И А.и.

________________________________________ гаризасын караганнан соң карар бирде:

Бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне __________________________ сәбәпле, кире кагарга

__________________________________________________________________________________

________

өстәмә гарантияләр турында Нигезнамәнең 2.8 пункты нигезендә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагуның сәбәбен күрсәтергә

__________________________________________________________________________________

________

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

________________

Комиссия рәисе ______________________

______________

имзасы И.А.и. фамилиясе